ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.10.2023 Казан ш. № 209

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булып, вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законны, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указларын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булып, вазыйфа биләгәндә Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булып, вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2022 елның 13 декабрендәге 238 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының _____ елның
«__» _______________
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булып, вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның иң югары төркемендәге вазыйфалары:

рәис урынбасары, 2 штат берәмлеге.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларның төп төркемендәге вазыйфалары:

туризм эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу бүлеге җитәкчесе;

туризм продуктын таныту бүлеге җитәкчесе;

туризм индустриясен үстерү бүлеге җитәкчесе;

дәүләт программаларын үстерү һәм гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе;

хезмәткәрләр һәм хокук эше бүлеге җитәкчесе;

финанс, дәүләт заказы һәм мобилизация эше бүлеге җитәкчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркемендәге вазыйфалары:

дәүләт программаларын үстерү һәм гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

хезмәткәрләр һәм хокук эше бүлегенең әйдәп баручы консультанты.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге вазыйфаларның әйдәп баручы төркеме вазыйфалары:

финанс, дәүләт заказы һәм мобилизация эше бүлегенең әйдәп баручы белгече, 2 штат берәмлеге;

туристлык индустриясен үстерү бүлегенең әйдәп баручы белгече

___